**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2022 елның 14 ноябре** **№ 4**

**Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Люгдон поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 24 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Люгдон поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Люгдон поселогы, Лесная ур., 3 адресы буенча урнашкан йорт янында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Люгдон поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- урам яктырткычларын урнаштыру, монтажлау, электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары сатып алу;
- Люгдон поселогы урам юл челтәрен карап тоту (дизель ягулыгы сатып алу)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Түбән Үрәс авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы В.Г.Сафаров